РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани, дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» июня 2026 ел. № 16

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге генераль планы проектын карау буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексын, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә, Әтнә муниципаль районында җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән карар итәм:

1. Олы Әтнә авыл җирлегендә яшәүчеләр катнашында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге генераль планы проектын карау буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә;
2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәш бирү органы составын расларга:
- Татарстан Республикасының Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Каюмов;
- Татарстан Республикасының Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Л.Халиков;
- Әтнә район башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;
- Татарстан Республикасының Әтнә муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Р.Ф.Фазлиәхмәтов;
- Татарстан Республикасының Әтнә районы башкарма комитетының хокук бүлеге начальнигы Г.К.Мортазина;
- Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Р. Маликова;
- “Татарстан Республикасының пространство белешмәләре фонды” дәүләт бюджет учреждениесы вәкиле (килешү буенча).
3. Үткәрү вакыты һәм урыны:
25.06.2026 ел. 9:00 - Олы Әтнә авылы, ш. Мәрҗани ур., 6 й.;
25.06.2026 ел. 10:00 - Яңа Әтнә авылы, Совет ур., 7А-мәдәният йорты бинасы;
25.06.2026 ел 11:00 - Кече Әтнә авылы, К. Маркс ур., 26 йорт – мәчет янында;

25.06.2026 г. 13:30 - Шеканясь авылы, Татарстан ур., 18-балалар мәйданчыгы янында;
25.06.2026 ел 14:30 - яңа Юлба авылы, Үзәк урам, 12а йорт – мәчет янында.
4. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.
5. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты кызыксынучы затларны үткәрү турында хәбәр итүдән алып, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы йомгакны бастырып чыгарту көненә кадәр бер айдан артмаска тиеш;
6. Татарстан Республикасының Әтнә районы башкарма комитеты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеш кодексының 5.1 нче матдәсендә каралган, иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр әзерләргә;
7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (atnya.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
8. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль
районы башлыгы

Р.Ш.Хисамиев